| КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО СОЦИАЛЬНО-ЭКОНОМИЧЕСКОМУ МОНИТОРИНГУ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ МОНИТОРИНГ КОМИТЕТЫ |
| --- | --- | --- |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.01.2018 г. Казань № 1-ос

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга карата таләпләрне үтәү комиссиясе турында Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетының 17.03.2016 № 6-ос боерыгы белән расланган нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга карата таләпләрне үтәү буенча комиссияләр турында» Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы № ПУ-569 Указы нигезендә, б о е р ы к б и р ә м:

1. «Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга карата таләпләрне үтәү комиссиясе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетының 17.03.2016 № 6-ос боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәттәге тәртибенә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга карата таләпләрне үтәү комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле 21.1 пункт өстәргә:

«21.1. Әлеге Нигезләмәнең 17, 19, 20 пунктларында каралган дәлилләнгән бәяләмәләрдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә һәм хәбәрнамәләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) гарызнамәләр нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынучы оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 30, 34, 36 пунктлары яисә бүтән карар нигезендә карарларның берәрсен кабул итү өчен рекомендацияләр.».

2. Юридик сектор әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәве узуын тәэмин итәргә тиеш.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны рәис урынбасары О.Ю.Семеновага йөклим.

Рәис В.П.Кандилов